| | |
|---|---|
| ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 23 октябре Лениногорск № 210

Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналашуы картасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясына, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертү проекты буенча фикер алышу нәтиҗәләрен карап, Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналашуы картасына үзгәрешләр кертергә:

– ТР, Лениногорск ш., Школьная ур., 16 адресы буенча урнашкан 16:51:010601:97 җир участогына карата, шәхси торак төзү максатларында, Д-3 территориаль зонасын (мәгариф һәм фәнни комплекслар урнаштыру зонасы) Ж-1 территориаль зонасына (шәхси торак йортлар төзү зонасы) үзгәртү;

– ТР, Лениногорск ш., Корчагин ур., 8а йорт адресы буенча урнашкан 800 кв. м мәйданлы, 16:51:012401:1657 номерлы җир участогын,территориаль зонаны

гамәлдәге зонадан файдалануга китерү максатларында, капиталь төзелеш объектын – административ-көнкүреш биналары урнаштырылган автомойка-капиталь төзелеш объектын гамәлдәге зонага туры китерү максатларында, Р-1 территориаль зонасының өлешен (рекреацион-ландшафт территорияләре зонасы) ИТ-4 зонасына (транспорт инфраструктурасы объектлары зонасы) үзгәртергә;
– Элеккеге «Каенкай» бакчачылык җәмгыяте территориясенә карата, әлеге территорияне факттагы куллануга туры китерү, планлаштыру берәмлеге – квартал чикләрендә индивидуаль торак төзелеше максатыннан, Ж-4 территориаль зонасын (бакчачылык һәм яшелчәчелек зонасы) Ж-1 территориаль зонасына (шәхси торак йортлар төзү зонасы) үзгәртергә.

2. Җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналашуы картасына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә һәм яңартылган документларны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Россия Федерациясе территориаль планлаштыруның федераль геомәгълүмат системасында (ФГИС РТ) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://Leninogorsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Карар үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. Н. Карасевка йөкләргә.

Лениногорск шәһәре муниципаль
берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов